# КЕРЕШ СҮЗ

Сөйләмә тел иҗтимагый тормышның төрле тармакларында кулланыла. Аеруча укытучылар, лекторлар, актёрлар кебек белгечләрнең сөйләме әдәби нормаларга нигезләнә. Татар әдәби теленең сүзлек составында, грамматик төзелешендә, авазлар системасында да билгеле нормалар бар. Бу нормаларның кайберләре һәм язма телгә, һәм сөйләмә телгә куелган булса, кайберләре язма телгә генә яки сөйләмә телгә генә куелган.

Дөрес язу нормалары, борынгычарак әйтсәк, имла кагыйдәләре, язма телгә генә карый. Сүзнең язылышын билгели торган кагыйдәләр *орфография* дип атала. Сөйләмә телгә исә әйтелеш һәм басым нормалары карый. Сөйләмә телгә карата билгеләнгән кагыйдәләр системасы *орфоэпия* дип атала. Орфоэпик нормалар, яки сөйләм нормалары, хәзерге әдәби телнең үзен тәшкил итә. Алар классик татар телен оештыру өчен зарур, алардан файдалана белү – кешенең белемле, укымышлы, сәвәтле булуы билгесе.

Орфоэпик нормаларны чагылдыру өчен, *орфоэпик сүзлекләр* төзиләр. Орфоэпик сүзлекнең төп максаты – әйтелеше яки басым куелышы ягыннан кыенлык тудырган сүз хакында мәгълүмат бирү. Ягъни бу төр сүзлекләр башкалардан сүзне тасвирлау рәвеше белән аерыла, аларда сүзләр фәкать орфоэпик аспектта гына ачыклана.

Әлеге сүзлекне төзегәндә дә югарыдагы максат күз уңында тотылды, шуңа күрә анда аңлатмалы сүзлектәге кебек аңлатмалар, сүз төркемен белдергән һәм стилистик тамгалар, сүзнең килеп чыгышы турында һ. б. ш. мәгълүматлар бирелмәде. Мәгәр нинди дә булса сүзнең әйтелеше, басымы яки форма ясалышы аерым ачыкламадан башка аңлашылып бетмәсә я буталчык тудырса, кыска һәм шартлы гына аңлатма яки башка мәгълүмат бирелде.

Сүзлеккә турыдан-туры орфографик бурычлар куелмады, әмма, татар теленең башка сүзлекләре кебек үк, бу орфоэпик сүзлек тә гамәлдәге орфографик кагыйдәләр нигезендә төзелде, шуңа күрә ул лөгатьлегенә кертелгән сүзләр күләмендә орфографик сүзлек буларак та кулланыла ала.

Сүзлекнең лөгатьлегенә исә, актив кулланышта йөргән сүзләрдән тыш, беренче нәүбәттә әйтелеше язылышына тәңгәл килмәгән, басымын куюда авырлык тудырган, грамматик формалары ясалганда басым гомуми кагыйдәгә күрә соңгы иҗеккә күчмәгән һ. б. ш. лексик берәмлекләр кертелде. Хәзерге татар лексикасын киңрәк колачлап, лөгатьлекне киңәйтү максаты куелмады.

Орфоэпик сүзлек төзү эшенә беренче алынучылардан түгелбез. Моңарчы да татар теленең мондый типтагы сүзлекләре төзелгәне бар. Тәүге орфоэпик сүзлекне 1995 елда фонетист галим Х. Х. Сәлимов әзерләп бастырган. Әлеге белешмәлектә һәр сүзнең фонетик транскрипциясе бирелгән. Басым баш сүздә түгел, җәяләр эчендәге транскрипциядә күрсәтелгән. Вокабула буларак сүзлеккә гади лексик берәмлекләр дә, сирәк кенә сүзтезмәләр һәм фразеологик берәмлекләр дә алынган. Кисәкчәләр һәм бәйлекләрнең басымнарын күрсәтү аерым торган очраклар белән генә чикләнелмичә, аларның проклитика яки энклитика булып килгәндә басымны алмаулары да чагылдырылган.

Шул ук авторның 2004 елда нәшер ителгән «Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге» дә әүвәлге сүзлек принциплары нигезендә төзелгән, аның лөгатьлеге киңәйтелгән, тәртибе яңа алфавитка салынган, ләкин бу белешмәлектә авторның кайбер сүзләрнең әйтелешенә карата фикере үзгәргәнлеге күренә. Алдагы сүзлектән аермалы буларак, монысында баш сүзнең латиницада язылышы да тәкъдим ителгән.

Югарыдагы ике сүзлектә дә рус, рус теле аша кергән Европа телләре алынмаларының татар телендә үзләшкәннәре дә, үзләшмәгәннәре дә юк дәрәҗәсендә аз бирелүе күзәтелә. Кереш сүзләреннән күренгәнчә, автор аларны чагылдыруны бурыч итеп тә куймаган. Хәлбуки әнә шул алынмаларның әйтелеше, алардагы басымның урыны, күчү-күчмәве еш кына сорау тудыра.

Татар теленең моңа кадәр нәшер ителгән орфоэпик типтагы лексикографик чыганаклары шушы ике сүзлек белән чикләнә.

Яңа орфоэпик сүзлекне төзегән чакта, бу белешмәлекләр төп ориентир буларак файдаланылды. Алардагы бүгенге татар теленә хас орфоэпик нормаларны чагылдыру ноктасыннан уңышлы дип табылган сыйфатлар әлеге сүзлектә дә мөмкин кадәр исәпкә алынды, яңа принциплар нигезендә үстерелде.

Яңа сүзлектә төрләнә торган сүзләрнең ялгыш әйтелеш яки ялгыш басым төшерү ихтималы булган грамматик формаларының тутырып язылган рәвеше тәкъдим ителде. Элегрәк чыккан орфоэпик сүзлекләрдән аермалы буларак, сүзнең тулы фонетик транскрипциясе бирелмәде, мәгәр әйтелеше берничә төрле була алган иҗек яки иҗекләр генә күрсәтелде. Беренчедән, болай бирелеш сүзнең әйтелештә кыенлык тудырган урынын билгели. Икенчедән, лөгатьлектәге һәр сүзнең һәм грамматик формаларның транскрипциясе бирелсә, җәяләр, символлар, аларның күп булуы сәбәпле, сүзлек материалын визуаль кабул итүдә кыенлык туачак. Өченчедән, орфоэпик сүзлекнең төп бурычы фонетик транскрипция бирү дә, әйтелештәге элизия, редукция һ. б. ш. кебек бөтен аваз үзгәрешләрен чагылдыру да түгел (болар – тел белеменең фонетика, фонология тармаклары өйрәнә торган күренешләр).

Әйтергә кирәк, башка телләрнең орфоэпик сүзлекләрендә транскрипция мәсьәләсе төрлечә хәл ителгән. Татар теленең Х. Х. Сәлимов төзегән белешмәлекләрендә ул эзлекле рәвештә һәр сүзгә тәкъдим ителгән. Немец теленең орфоэпик сүзлегендә лөгатьлектәге сүзләргә бирелгән, грамматик формаларга бирелмәгән. Рус теленең безгә таныш булган бер генә орфоэпик сүзлегендә дә лөгатьлектәге сүзләрнең фонетик транскрипциясе бирелмәгән, фәкать әйтелеш белән язылышта аерма булган иҗек яки хәрефләр тезмәсе генә күрсәтелгән. Без үрнәк итеп соңгы типтагы сүзлекләрне алдык. Грамматик формаларның да, баш сүзләрнең дә әйтелешен күрсәтеп бирү, шиксез, белешмәлектән файдалануны, мәгълүматны кабул итүне катлауландырачак. Бәлки, киләчәктә, сүзлекнең алдагы басмаларында, грамматик формаларны исәпкә алмыйча, вокабула итеп бирелгән сүзләрнең генә тулы транскрипциясен бирү дә уңышлы булыр.

Транскрипция бирелгәндә, фонетик алфавит тамгаларыннан файдаланыла. Татар тел белемендә гомумкабул ителгән фонетик алфавит билгеләре юк. Ягъни төрле елларда чыккан хезмәтләрдә төрле билгеләр кулланылган һәм кулланылып

килә бирә. Сүзлектә фонетик транскрипция өчен нигез итеп, беренчедән, моңарчы чыккан орфоэпик сүзлекләрдәге билгеләр кулланылды; икенчедән, «Советская тюркология» журналы редакциясе тарафыннан кабул ителгән латиница нигезендәге халыкара фонетик транскрипциядәге кайбер билгеләр өлге буларак алынды. Кайбер яңа билгеләр исә авторларның фикер алышуы нәтиҗәсендә кабул ителде. Хосусан, татар теленә хас кыска *э* (эшче), *о* (олы), *ы* (ышкы) авазлары [ĕ], [ŏ], [ы̆] шәкелендә бирелде, *бре́ве* тамгасы (˘ – шулай ук *кра́тка* яки *дуга*) бу очракта авазның кыскалыгын күрсәтү билгесе буларак алынды. [ө] авазы өстенә исә андый тамга кую кирәк табылмады, чөнки бу билге әйтелеше татарчадан аерылган алынмаларда кулланылмый һәм башка авазлар белән бутала алмый.

Өсләрендә дуга тамгасы булмаган [а], [е], [о] авазлары, кагыйдә буларак, рус һәм Европа телләре алынмаларының әйтелешен биргәндә ([а°] авазына каршы куелып, [а] шулай ук татар сүзләренең икенче һәм аннан соңгы иҗекләрендә) кулланылды.

Кайбер хезмәтләрдә, алынма сүзләрдәге авазларны белдерер өчен, [ā], [ē], [ō], [ы̄] билгеләреннән файдаланыла. Халыкара транскрипциядә хәреф өстендәге сызык аның озынлык билгесе хезмәтен үти, шуңа күрә әлеге сүзлектә мондый тамгалардан баш тартылды, чөнки татар телендә андый озын сузыклар юк (чаг.: кырг. *тоо* [тō] ‘тау’).

Сүзлектә кулланылган яңа билгеләр – [ў] һәм [ү̆]. Авторлар фикеренчә, кайбер хезмәтләрдә [w] билгесе белән бирелгән өрелмәле ирен-ирен авазы *тау* [та́°w] һәм *дәү* [дә́w] кебек сүзләрдә катылык-йомшаклык нигезендә дифференциацияләнә, әмма транскрипциядә бу күренеш чагылмый, шул сәбәпле яңа билгеләр кулланырга дигән карар кабул ителде. Чаг.: *дәва* [дәўа́] – диал. *дәвә* [дәү̆ә́]. Мондый мисалларда [w] билгесе катылык-йомшаклык аермасын бирә алмый. Әлеге үзенчәлек яңа билгеләр куллану кирәклеге турында сөйли.

Орфоэпия, дөрес әйтү кагыйдәләре белән берлектә, диалекталь һәм гади сөйләм әйтелешләрен кире кага һәм халык арасында әдәби әйтелеш нормаларын урнаштыруны максат итеп куя. Орфоэпик сүзлек әдәби әйтелеш нормасын терки, шул ук вакытта әдәби тел кысаларында кулланылган вариантларны да исәпкә ала. Аерым берничә очракны санамаганда, сөйләм

теленә хас лексик вариантлар сүзлектә чагылдырылмады (к. *пальто – пәлтә*).

Әйтелеш вариантларына килгәндә, кайбер очракларда бер генә әйтелешне норма дип катгый билгеләү кыенлык тудыра. Теоретик хезмәтләрдә, мәс., академик грамматикаларда, билгеле аваз тезмәләре бер-берсенә тәэсир итешү нәтиҗәсендә ассимиляция барлыкка килүе һәм бу күренеш татар теле өчен норма дип күрсәтелә. Бу исә бик күп сүзләрнең язылышы белән укылышы арасында аерма барлыкка китерә. Мондый чакта гап-гади сорау туа: әгәр дә татар теле вәкиле ассимиляция күзәтелгән кайбер сүзләрне язылганча әйтсә, бу норманы бозумы? Бу сорауга кистереп бертөрле генә җавап бирү җиңел түгел, шуңа күрә сүзлекне төзүчеләр, кайбер очракларда әйтелештә вариант була алу ихтималын таныган хәлдә, ике әйтелеш вариантын бирүне тиеш таптылар. Мондыйлардан тыш, кайбер лексик берәмлекләрнең берничә вариантта кулланылышы һаман актив саклана (*җизни – җизнә*). Болар арасыннан берсенең генә әйтелешен дөрес дип тану икенчесенең әйтелешен хатага чыгару була. Телнең хәзерге үсеш этабында мондый адымга бару урынлы түгел дигән карашта торабыз.

Болардан тыш, телнең үсеш процессында кайбер аваз тезмәләре очраган сүзләр ике тармакка аерылган. Мисал өчен, [-рк-], [-лк-], [-нч-], [-рт-] һ. б. берничә аваз тезмәләре булган фигыльләрнең кайберләре әдәби телдә бертөрле генә әйтелә: *курык – курка; калык – калка*. Кайберләре исә актив рәвештә ике вариантта йөри: *йолык, йолкы – йолка, йолкый*. Мондыйларның ике вариантын куллану да норма чикләреннән чыгу түгел дип табылды.

Басым сүзне оештыруда мөһим роль уйный. Күп очракта язылышлары бер үк төрле булган сүзләрнең мәгънәләрен басымны дөрес кую белән генә аерып була (*тутыккан йолдызча́* – исем, *йолды́зча ел* – сыйфат; *кыска сызыкча́* – исем, *сызы́кча тигезләмә, сызы́кча тизлек* – сыйфат).

Татар телендә басым һәрвакыт сүзнең соңгы иҗегенә төшә, дигән караш бар, ләкин ул дөреслеккә туры килеп бетми. Төрле сүз төркемнәрендә ул төрле иҗеккә төшә ала. Башлыча, татар басымы, сүзгә кушымча ялганган саен, соңгы иҗеккә күчә бара, ләкин басымны үзләреннән үткәрми торган кушымчалар да бар: 1) *-мы/-ме* сорау кушымчасы; 2) *-ма/-мә, -мый/-ми* юклык кушымчалары; 3) *-ча/-чә, -дай/-дәй* рәвеш ясагыч

кушымчалар. Хәбәрлек кушымчалары да басымны үзләренә алмый: *төзүче́мен, укытучы́сың*.

Фигыльләрдә басым төшү күп кенә шартларга бәйле. Басым төшү кагыйдәләрен сүзлек керешендә бирүнең кирәге юк, шулай да бер генә хосуска тукталмыйча ярамый. Боерык фигыльдә басым һәрвакыт (!) беренче иҗеккә төшә дип кабул ителгән. Бу мәктәп дәреслекләреннән алып югары уку йортлары өчен әзерләнгән дәреслекләрдә, хәтта академик грамматикаларда да эзлекле рәвештә шулай күрсәтелә, әмма үрнәк итеп икеиҗекле фигыльләр (*у́тыр, у́кы*) яисә юклык кушымчасы белән килгән бериҗекле фигыльләр (*ба́сма, ки́тмә*) тәкъдим ителә. Өч һәм өчтән артык иҗекле боерык фигыльләрдә исә бу кагыйдәне үтәү мөмкин дә түгел кебек (*ка́нәгатьләндер, а́ралаштыр* – ?). Аеруча боерык фигыль катгый боеруны гына түгел, үтенүне, йомшак кына нәрсәдер сорауны да белдерә. Системалы анализ ясаганда, боерык фигыль формаларында да басым соңгы иҗеккә төшкәне ачыклана. Басымның беренче иҗеккә төшүе исә – әйтелеш интонациясенә бәйле күренеш, шуңа күрә сүзлектә күрсәтелми.

«Татар теленең орфоэпик сүзлеге» төзүчеләрнең хәзерге татар әдәби әйтелешенә карата булган карашларын чагылдыра. Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru

*Р. Т. Сәфәров*